РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

улица Бебеля, дом 129,
город Чистополь, 422980

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

Бебель урамы, 129 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

тел. (84342) 5-43-60, тел/факс 5-43-70, E-mail: chistay@tatar.ru

**№ 35/1** **2018 елның 18 июле**

***Решение*** ***Карар***

2018 елга һәм 2019-2020 еллар
план чорына Татарстан Республикасы
«Чистай муниципаль районы» муниципаль
берәмлеге бюджетына үзгәрешләр кертү турында

Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе Карманова Наталья Анфиногентовнаның "2018 елга һәм 2019-2020 елларның планлы чорына Татарстан Республикасы "Чистай муниципаль районы" муниципаль берәмлеге бюджетына үзгәрешләр кертү турында" докладын тыңлап фикер алышканнан соң, Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Советының «2018 елга һәм 2019-2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2017 елның 13 декабрендәге 27/2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 2018 елга Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең гомуми күләме 1376454,3 мең сум күләмендә;

2) «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 1402601,4 мең сум күләмендә;

3) «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгының иң чик күләме 26147,1 мең сум күләмендә».

2. 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) 2019 елга Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 1225369,25 мең сум һәм 2020 елга 1238758,91 мең сум күләмендә;

2) «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме:
- 2019 елга 1225369,25 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы расланган чыгымнар 14368,0 мең сум күләмендә;
- 2020 елга 1238758,91 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 28582,0 мең сум күләмендә.
3) «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгы:
- 2019 елга нульгә тигез;
- 2020 елга нульгә тигез.»;

1.2. «2018 елга Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары» 1 нче кушымтасын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә бәян итәргә;

1.3. «2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары» 2 нче кушымтасын әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә бәян итәргә;

1.4. «2018 елга Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетының фаразлана торган керемнәре күләмнәре» 3 нче кушымтасын әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә бәян итәргә;

1.5. Приложение №4 «Объемы прогнозируемых доходов бюджета муниципального образования «Чистопольский муниципальный район» Республики Татарстан на плановый период 2019 и 2020 годов» изложить в редакции согласно приложению № 4 к настоящему решению;

1.6. «2018 елга һәм 2019-2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәренең югары дәрәҗәдәге дәүләт хакимияте органнарының баш администраторлары исемлеге» 6 нчы кушымтасын әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә бәян итәргә;

1.7. «2018 елга Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» 8 нче кушымтасын, барлык күчешләрне исәпкә алып, әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә;

1.8. «2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» 9 нчы кушымтасын, барлык күчешләрне исәпкә алып, әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә;

1.9. «2018 елга «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен чыгымнарны классификацияләү бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре) буенча бүлү» 10 нчы кушымтасын, барлык күчешләрне исәпкә алып, әлеге карарга 8 нче кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә;sub_1007

1.10. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2019 һәм 2020 еллар план чорына чыгымнарны классификацияләү төрләре төркемнәренә, бүлекчәләре,

максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре) буенча бүлү» 11 нче кушымтасын, барлык күчешләрне исәпкә алып, әлеге карарга 9 нчы кушымта нигезендә бәян итәргә;

1.11. 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күләмен расларга:

- 2018 елга, әлеге карарга 18 нче кушымта нигезендә бүлү белән, 1,1 мең сум күләмендә;
- 2019 елга 1,1 мең сум күләмендә, 2020 елга 1,2 мең сум күләмендә, әлеге карарга 19 нчы кушымта нигезендә бүлү белән.»;

1.12. «2018 елга Чистай муниципаль районының авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр» 18 нче кушымтасын әлеге карарга 10 нчы кушымта нигезендә бәян итәргә;

1.13. «2019-2020 еллар план чорына Чистай муниципаль районы авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр» 19 нчы кушымтасын әлеге карарга 11 нче кушымта нигезендә бәян итәргә;

1.14. 13 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертларны Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетында исәпкә алырга:

- 2018 елда 809708,3 мең сум күләмендә әлеге карарга 22 нче кушымта нигезендә;
- 2019 елда 667392,2 мең сум һәм 2020 елда 667138,21 мең сум күләмендә, әлеге карарга 23 нче кушымта нигезендә.

2. Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетында «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертларны исәпкә алырга:

- 2018 елда әлеге карарга 24 нче кушымта нигезендә 21288,4 мең сум күләмендә.»;

1.15. «2018 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына күчерелә торган бюджетара трансфертлар» 22 нче кушымтасын әлеге карарга 12 нче кушымта нигезендә бәян итәргә;

1.16. «2019-2020 елларга Татарстан Республикасы бюджетыннан «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына күчерелә торган бюджетара трансфертлар» 23 нче кушымтасын әлеге карарга 13 нче кушымта нигезендә бәян итәргә;

1.17. «2018 елда «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетыннан күчерелә торган бюджетара трансфертлар» 24 нче кушымтасын әлеге карарга 14 нче кушымта нигезендә бәян итәргә;

1.18. Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарына 97979,1 мең сум күләмендә кире кайтарылмый торган кертемнәр хисабына үзгәрешләр кертергә, шул исәптән:

арттырырга:

«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» 802 ведомствосы буенча 52293,8 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы җирлекләре бюджетларына бюджетара трансфертлар күчерүгә әлеге карарга 15, 16 нчы кушымталар нигезендә;
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» 803 ведомствосы буенча 635,4 мең сум күләмендә;
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы» 810 ведомствосы буенча 1772,7 мең сум күләмендә;
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты» 811 ведомствосы буенча 19645,3 мең сум күләмендә;
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Контроль-хисап палатасы» 812 ведомствосы буенча 14,8 мең сум күләмендә;
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» 817 ведомствосы буенча 18246,8 мең сум күләмендә;
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге» 819 ведомствосы буенча 4156,2 мең сум күләмендә;
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының спорт бүлеге» 821 ведомствосы буенча 1214,1 мең сум күләмендә;

1.19. «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарын 2018 елның 01 гыйнварына үз акчаларының калган өлеше исәбеннән 2214,1мең сум күләмендә арттырырга, шул исәптән:
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты» 811 ведомствосы буенча 2214,1 мең сум күләмендә;

1.20. Чистай муниципаль районы бюджеты чыгымнарын «Чистай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» 802 «Резерв фондлары» 0111 бүлекчәсе буенча 2013,5 мең сум күләмендә киметергә;

1.21. Чистай муниципаль районы бюджеты чыгымнарын арттырырга 2013,5 мең сум күләмендә шул исәптән:
«Чистай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» 802 ведомствосы буенча 237,3 мең сум күләмендә, шул исәптән Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы бюджетларына бюджетара трансфертларны күчерүгә 237,3 мең сум күләмендә, әлеге карарга 17 нче кушымта нигезендә;
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» 803 ведомствосы буенча 400,0 мең сум күләмендә;
«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты» 811 ведомствосы буенча 1376,2 мең сум күләмендә;

1.22. Әлеге карарның 18 нче кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарына үзгәрешләр кертергә, «Чистай муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» 802 ведомствосы буенча җирлекләр бюджетларының бюджетара трансфертларын арттырып 122,4 мең сум күләмендә;
ведомстволардан күчешләр исәбенә:
«Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты» 811 ведомствосыннан 122,4 мең сум күләмендә.».

2. “Чистопольские известия” һәм “Чистай хәбәрләре” газеталарында яисә

“Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы”нда (pravo.tatarstan.ru) әлеге карарны бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Советының бюджет һәм фаразлау буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
башлыгы Д.А. Иванов